**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2017 ел, 21 февраль № 110

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы турындагы нигезләмәне һәм Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы составын раслау хакында» 2016 ел, 24 октябрь, 775 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы турындагы нигезләмәне һәм Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы составын раслау хакында» 2016 ел, 24 октябрь, 775 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы турында нигезләмәдә:

3.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Эксперт советы карарлары кирәк булган очракта үткәрелә торган утырышларда эксперт советы әгъзалары тавышларының гади күпчелеге нигезендә кабул ителә.

Эксперт советы утырышын эксперт советы рәисе алып бара, ул булмаган очракта аның вазыйфалары утырышта катнашучы эксперт советы әгъзаларының берсенә йөкләнә. Тавышлар тигез булганда эксперт советында рәислек итүче

тавышы хәлиткеч санала. Эксперт советының җаваплы секретаре вакытлыча булмаса, аның вазыйфалары эксперт советы утырышында катнашучы башка затка йөкләнә.

Эксперт советы утырышында эксперт советы әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, ул хокуклы санала.

Эксперт советының һәр әгъзасы эксперт советы утырышында яки язма формада аерым фикерен белдерергә хокуклы, һәм ул эксперт советы утырышы беркетмәсендә күрсәтелә.

Эксперт советы карарлары эксперт советы рәисе һәм эксперт советының җаваплы секретаре тарафыннан имзалана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

Эксперт советы карарлары «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 ел, 22 июль, ФЗ-116 нчы Федераль законда билгеләнгән вакытта Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрелә.».

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы составында:

совет составыннан И.П.Субботинаны чыгарырга;

совет составына Владимир Игоревич Зерковны – Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы Төбәк үсеше департаментының махсус икътисадый зоналарны төзү һәм стратегик үстерү бүлеге башлыгын (килешү буенча) кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\110.docx